**Җәүһәрова Ф.Х.**

**КФУ доценты**

**Гыйльметдинова Н.Н.**

**КФУ, 1101 төркем студенты**

# КИЧКЕ УЕН КОМПЛЕКСЛАРЫ КОНТЕКСТЫН ТУПЛАУ

Адәм баласын туганнан алып, үсеп буй җиткәнгә кадәр озата барган төрле хәрәкәтле, сүзле, җырлы, биюле уеннар яшәп килә. Алар күңел ачу, ял итү, организмны чыныктыру, танышу-кавышу кебек функцияләрне үтәү максатыннан уйналырга мөмкин. Шул рәвешле, уеннар халыкның аңын, көнкүрешен чагылдырган бер өлеше булып торалар. Татар халкының драматик иҗаты һәм уеннарына игьтибар, аларны күпләп бастырып чыгару эше татарларда XIX гасырда башланып, бүгенге көндә дә фольклористиканың иң игътибар үзәгендә булган өлкә.

Татар уеннарының беренче язып алынган үрнәкләре белән без XI гасыр язма истәлеге – М.Кашгарыйның “Диваане лөгатет-төрк” хезмәтендә очрашабыз.

Балаларның уенга бәйле фольклорының әһәмиятен аңлап, махсус җыю һәм бастырып чыгару эше К.Насыйри, Х.Бәдигый, Н.Исәнбәт, Г.Рәхим, Г.Колаткы, Г.Хәбиб тарафларыннан башлап җибәрелә.

Соңгы елларда уеннарны, шул исәптән йола уеннарын өйрәнү буенча Ф.Урманчеев, И.Надиров, Х.Гатина, Р.К.Уразманова, Ф.Баязитоваларның эшчәнлекләре билгеле.

Шулай ук соңгы чорда Татарстанның Мәдәният министрлыгы каршындагы эшләп килүче фольклор үзәге тарафыннан чыгарылган халык иҗаты һәм йолаларына багышланган җыентыклар да уеннарны туплау һәм өйрәнүдә зур роль уйнадылар.

Хәзерге фольклористикада уенга бәйле фольклорны функциональ яктан, ягъни нинди вазыйфа башкаруына, кулланылыш максатына бәйле рәвештә төркемләү гамәлгә кергән. Шартлы рәвештә уеннарны “балалар

уеннары” һәм яшьләр уйнаган, “кичке уеннар” төркемнәренә бүлеп булыр иде. Ләкин уеннарны болай бүлү шартлы рәвештә эшләнә. Чынлыкта, уеннарның табигый яшәешендә бу чикне сызу – шактый кыен мәсьәлә. Әмма шулай да яшьләр һәм олылар тарафыннан уйнала торган уеннар эчтәлекләре белән беркадәр аерылып торалар. “Зурлар уеннары күңел ачуга гына түгел, ә еш кына йолалык мәгънәсенә ия була яки үз парыңны эзләү, яраткан кешең белән көрешү, кавышу чарасы да булып тора. Зурларның уеннары тормыш-көнкүреш, кеше яшәеше белән тыгызырак бәйләнгән. Өлкәннәр тарафыннан уйнала торган уеннарны төркемләүдә безнеңчә, И. Надиров бүленеше бик кулай. Ул аларны, уйналу рәвешләренә карап, түбәндәге төркемнәргә аера: “Фант җыю һәм һөнәр күрсәтү белән бәйле уеннар”, “Каршы сафларга тезелеп һәм парлашып уйналучы уеннар”, “Әйлән-бәйлән, түгәрәк уеннары” [1, 45].

Р.Ягъфәров исә, өлкәннәр репертуарындагы уеннарны дүрт төркемгә бүлә: календарь йола уеннары, көнкүреш йола уеннары һәм күңел ачу уеннары; күңел ачу тамашалары һәм халык театры [2, 123].

Ә хәзер безнең өйрәнү объекты булып торган яшьләр тарафыннан уйналган кичке уеннарны карап китик, Р.Ягъфәров төркемләвендә ул күңел ачу уеннарына кертелеп карала.

Яшьләрнең күңел ачу уеннары белән балалар репертуарындагы уеннар ни белән аерыла сон? Монда иң беренче уенның эчтәлегенә мөнәсәбәтле аермалыкны билгеләргә мөмкин. Балалар уеннарында хәрәкәт, физик чыныгу беренче планга чыга. Шулай ук драмалылыкка омтылу, образларга кереп уйнау – балалар уеннарының төп үзенчәлекләреннән. Ә яшьләр уеннарының төп үзенчәлеге – ул уеннарның эчтәлегендә яшьләрнең социальләшүенә бәйле темалар өстенлек итү. Икенче төрле әйтсәк, конкрет бер авылда яшәүче халыкның традицион аңында бик күптәннән формалашкан эстетик, этик, әхлакый идеаллары темалары: оста, уңган, булган егет яки кыз, мәхәббәт тугрылыгы, тиң пар сайлау һ.б. Бу – уен җырларының эчтәлегендә дә, уен хәрәкәтләрендә дә ачык чагыла. Дөресрәге, бу төр уеннарның төп вазыйфасы

яшь кешеләрнең үзләренә тиң парны эзләп табуга кайтып кала. Ләкин тиңлек мәсьәләсе бу авылның, ягъни социумның этик, эстетик, әхлакый идеаллары системасы белән билгеләнелә.  Хәрәкәт, җыр, көй, кыскасы, уен шушы максатка ирешүнең  төп чаралары булып аңлашыла. Ләкин ул гади түгел, ә халык эстетикасы белән өртелгән, гүзәл сәнгати рәвешкә кертелгән чара. Бу фикерләребезнең шулай икәнлеген без 2011 елгы җәйге фольклор практикасы кысаларында тупланган материаллар нигезендә дә дәлилли алдык. Хәзер шуларның кайберләренә күзәтү ясап китик.

Яшьләрнең кичке уеннары турындагы материалны без Теләче районы Олы Нырсы авылында яшәүче 78-80 яшьлек әби-бабайлардан  тупладык. Безнең төбәктә яшьләр уйнаган кичке уеннарның күпчелеге җырлы-биюле, күмәк күңел ачу уеннары “универсаль” характерда һәм ачык һавада уйналганнар.

Кичке уеннар, әби-бабайларның  сөйләүләренә караганда,  язгы ташулар булып узгач, җирләр кипкәч, болыннарда уйналган. Ләкин иң кызыгы, кешеләр күп җыелып, күмәкләшеп уйналганы авылда Сабантуй булып узган көннәрдә үткәрелгән. Кыр эшләре тәмамланып, үзенә күрә бер нәтиҗә ясаган бу авыл бәйрәмнәре атналар буе сузыла торган булган. *“Безнең Олы Нырсы авылында Сабантуй булган көнне кич белән бөтен тирә–күрше авыллардан яшьләр җыенга төшәләр. Икенче көнне Сабантуй Кече Нырсы авылында. Җыенга да шунда җыелабыз. Өченче көндә чират Бичергә.  Җыен да Бичердә гөрли! Һәм шулай атна-ун көн дәвам итә”*, - дип сөйли әбием – Гыйлметдинова Сәлимә. Бу көннәрдәге уенга яшьләр генә түгел авылның  өлкәннәре, барлык кайткан кунаклар да читтән карап торырга җыела торган булганнар. Шул рәвешле әлеге кичке уеннар көндезге Сабантуйларның бер дәвамы булып торган. Уенга яшьләр 15-16 яшьләрдә йөри башлаганнар. Яшьләр күп булганга,  түгәрәкләр дә күп була торган булган. Олыраклар бер түгәрәккә, яшьрәкләр аерым тупланып уйнаганнар. *“Ике егетнең берсе гармунда суза иде, гармунчылар гармуннарын алып җыен җиренә беренче килеп җитәләр”*, - дип  истәлекләре белән уртаклаша

икенче әби. *“Авылда кичке эшләр тәмамлану белән әле бер урамнан, әле икенчесеннән гармун тавышы ишетелә: яшьләр җыенга болынга төшәләр. Гадәттә шул сәгать ун, унберләрдә җыела тораганнар иде”*.

Кичке уеннарда яратылып уйналган “Наза”ны, “Ямьле” уеннарын, “Зәлидә”, ”Түгәрәк” уеннарын санап китәргә була. “Наза” уенының карасак, уен асылында парлашу, үзеңә тиң яр табу максаты ята. Уенга керер өчен үк синең инде парың булырга тиеш була, ләкин кызмы, егет кешеме мөһим түгел, ансы ничек туры килә шулай ярый. Парлашып яшьләр бер рәт булып тезелгәннәр. “*Барлыгы унлап, унбишләп пар була торган идек”*, дип сөйлиләр әбиләр. Уенның шарты буенча бер уенчы парсыз калырга тиеш. Яшьләр, әлеге парсыз кешегә атап, шул кешенең ниндидер сыйфатларын чагылдырган җыр җырлыйлар, кушымта барышында, бу кеше яшьләр ясаган капкадан ( алар бу вакытта тотынышкан кулларын өскә күтәреп торалар) чыга һәм үзенә пар сайлый. Әлеге пары белән ул теземнең артына барып баса. Әлбәттә, яшьләр гадәттә үзләренә пар итеп ошатып йөргән кыз яисә егетне сайлый торган булганнар. “Наза” текстлары гармунчы уйнаган көйгә салынып җырланган:

*Наза дигән кыз баланың*
*Бөрлегәне түгелгән,*
*Көн дә наза уйнаганга*
*Наза чыкмый күңелдән*
*Наза, Наза*
*Наза матур кыз бала.*

Шул рәвешле уен дәвам иткән. Шулай ук кулга-кул тотынышып, ләкин түгәрәккә басып уйналган икенче күмәк уен – “Ямьле” дип аталаган. Аны да яшьләр бик яратып уйнаганнар. *“Барысы да җитәкләшеп баскач, бик зур түгәрәк булыр иде”*, дип сөйли әбиләр. Уенга шулай ук гармунчы кирәк булган, гармунчы әлеге уенның көен сузып җибәрү белән, яшьләр акрын гына хәрәкәткә килеп, әйләнә башлап, түбәндәге куплетларны җырлаганнар:

*Ямьле Агыйдел буйлары,*

*Ямьле Агыйдел буйлары.*

*Ямьле, тәмле шул Агыйдел сулары,*

*Ямьле,тәмле шул Агыйдел сулары*

Шуннан икәү әйләнә уртасына чыгып басалар да кулларын тотып:

*Каз канаты каурый, каурый*

*Сәлам хат язарга ярый*

*Уйнамагач та көлмәгәч*

*Яшь гомер нигә ярый.* -

кебек җырлар башкарганнар, такмактан соң бу пар биеп алган, ә калган уенчылар бу вакытта кулларын чабып торганнар, ә парлашып уртага чыккан яшьләр биегәннән соң, яңадан әйләнәгә басканнар. Әйләнәдәгеләр тагын җырлап әйләнә башлаганнар:

*Каз канатларын санадым,*

*Тезелеп кагынганда.*

*Инде кемнәргә карармын,*

*Өзелеп сагынганда.*

Шунысы кызыклы әлеге уеннарның башы-азагы булмый, төрле җырлар, такмаклар белән бер өзлексез уйнала, уенчылар агым рәвешендә хәрәкәтләнәләр.

Димәк, кичке уен комплекслары контекстын туплау барышында, без текстлар язып, туплау белән генә чикләнмичә, ә уенның кайчан (тәүлекнең кайсы вакытында, елның кайсы фасылында һәм кайчанга кадәр уйналуын), кайда (урынын, авылда читтә, болында, урамда уйналганын), уенны яшьләрнең ничек уйнавы (ничек басулары, түгәрәккә, кулга-кул тотынышып, рәткә) тикшерергә һәм боларның барысын да җентекләп тупларга тырыштык. Димәк, фольклор күренешләрен болай функциональ яктан да, мәдәни контекст буларак та барлау - әлеге күренешләрне тулылыгы белән күзалларга мөмкинлек бирә.

**Кулланылган әдәбият исемлеге**

1. Надиров И.Н. Татар халык йола җырлары // Татар халык иҗаты13 томда, 8 том. - Казан: Тат кит. Нәшр., 1980, 3-16б.
2. Ягъфәров Р.И. Татар халык уеннары. – Казан: Тат. кит. нәшр. 1998, - 156 б.

**Чыганаклар:**

1.2011 ел фольклор практикасы кысаларында тупланган материаллар (инф.Гыйльметдинова Сәлимә,1933елда Теләче районы Олы Нырсы авылында туган, яши).

2. 2011 ел фольклор практикасы кысаларында тупланган материаллар (инф.Гобәйдуллин Гарифулла, 1928 елда Теләче районы Олы Нырсы авылында туган, яши).

3. 2011 ел фольклор практикасы кысаларында тупланган материаллар (инф.Хәйретдинова Нурлыгаян, 1932 елгы, Теләче районы Олы Нырсы авылында туган, яши).